| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>БИЛЯРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БИЛӘР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2022 с. Билярск № 40

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Биләр авыл җирлеге»муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлек Уставы нигезендә,

**Биләр авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советының 2013 елның 26 ноябрендәге №52 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» гы карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советының 2017 елның 1 августы № 49« Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»карары, 20.08.2018 № 73 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары,2019 елның 20 июнендәге № 103 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары, 15.08.2022 ел, № 34 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Биләр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә

үзгәрешләр кертү турында» карары, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» 2013 елның 26 ноябрендәге 52 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 16 сентябрендәге 35 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы» (https//fgis-tp.ru) рәсми сайтында һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https//alekseevskiy.tatarstan.ru), Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль**
**районы Биләр авыл җирлеге**
**Совет Рәисе** **Г. Г. Хәбибуллин**